**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 74-9 «26» август 2021 ел

Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен түләүсез тапшыруның уртача район нормасын билгеләү турында

Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының 26.11.2020 № 02-10656 номерлы хаты нигезендә, дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга хосусый милек буларак бирелә торган җир участокларының иң чик минималь күләмен билгеләү максатыннан,Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 40 статьясындагы 2 пункты нигезендә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән төзелә торган яңа җир кишәрлегенең минималь күләмен исәпкә алып,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте:

1. Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына гражданнарның милкенә җир кишәрлекләрен бушлай тапшыруның уртача район нормасын Азнакай муниципаль районы территориясендәге кануннар нигезендә 5 (биш) гектар күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис

М. З. Шәйдуллин